# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 4

апрель

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

Жор.

# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 4*
*апрель*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174  1996 елның 03.10 бирелде
Житештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1050 нөсхә. Заказы 0020-78
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н. Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хөзмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*

**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1999

Э ч т ә л е к

**I**

481. “Лицензияләү турында” *Татарстан Республикасы Законы* ......... 7

482.“Лицензияләү турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................................................ 22

483.”Югославия Союз Республикасындагы сугыш вакыйгалары белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....... 23

484.”Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 28 апрелендәге утырышы көн тәртибе турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 23

485.“Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* 25

486.”Татарстан Республикасының Су кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* 26

487.“Экологик экспертиза турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 26

488.“Алабуга” ирекле икътисадый зонасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ................ 27

489.“Татарстан Республикасы референдумы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 27

490.“Татарстан Республикасында товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сертификацияләү турында” Татарстан Республикасы законы хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................................................ 28

491.”1999 ел навигациясе башында “Татфлот” суднолар йөртү компаниясенең ягулык белән җитәрлек тәэмин ителмәве сәбәпле канәгатьләнерлек эшләмәве турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ................................................................................ 29

492."Казан-Чаллы юлының торышын яхшырту һәм анда травмаларын киметү чаралары турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 29

493."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законының 16 статьясының үтәлмәве хакында" Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 30

**II**

494."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясен чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 31

495."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 31

496."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 33

497."1999 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 33

498."1999 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 35

499."1999 елның II кварталына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эшен оештыру чаралары планы турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 36

500."Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясына өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 36

501."Туфракның уңдырышлылыгы турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 37

502."Татарстан Республикасында исемле хосусыйлаштыру исәпләре (кертемнәре) турында" Татарстан Республикасы Законының аерым

нигезләмәләрен аңлату хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 38

503."1999 елда Татарстан Республикасы халык депутатлары җирле Советлары эше турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 38

504."Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында булган тәкъдимнәр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .. 39

505."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 11 мартындагы XVIII пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тәкъдимнәре турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 39

506."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 24 мартындагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары әйткән тәкъдимнәр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 40

### III

507."Татарстан Республикасы Питрәч район хакимияте башлыгы карарын юкка чыгару турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 41

508."Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары системасында югары һәм баш административ дәүләт вазифалары буенча квалификация таләпләре турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 42

509."Татарстан Республикасы промышленность предприятиеләре һәм оешмаларының бурычларын еструктуралаштыру турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 43

510."1999 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында" *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........ 45

IV

511. "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турындагы күрсәтмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 номерлы карарының Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм гамәлдәге законнарга туры килү-килмәве турында" Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитеты бәяләмәсе ........................................ 46

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 481. Лицензияләү турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары белән юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар арасында Татарстан Республикасы законнары нигезендә лицензияләнергә тиешле эшчәнлекнең аерым төрләрен башкаруга бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм, лицензияләгәндә гражданнарның хокукларын җайга салу, аларның законлы мәнфәгатьләрен, әхлагын, гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында, дәүләтнең бердәм сәясәтен тәэмин итүгә, шулай ук бердәм базарның хокукый нигезләрен билгеләүгә юнәлдерелә.

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

– лицензия – лицензияләү таләпләрен һәм шартларын катгый үтәгән килеш, эшчәнлекнең лицензияләнүче төрен гамәлгә ашыру өчен юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга лицензияләүче орган тарафыннан бирелгән рөхсәт (хокук);

– эшчәнлекнең лицензияләнүче төре – Татарстан Республикасы территориясендә башкару өчен әлеге Закон нигезендә лицензия алуны таләп итә торган эшчәнлек төре;

– лицензияләү – лицензияләр бирүгә, лицензияләр булуны раслаучы документларны кабат рәсмиләштерүгә һәм лицензияләрне туктатып торуга һәм юкка чыгаруга, лицензияләнүче эшчәнлек төрләрен башкарганда лицензияләүнең тиешле таләпләре һәм шартлары үтәлешен лицензияләүче органнарның күзәтеп торуына бәйле гамәлләр;

– лицензияләү таләпләре һәм шартлары – норматив-хокукый актларда билгеләнгән таләпләр һәм шартлар бергәлеге, эшчәнлекнең лицензияләнүче төрен башкарганда аларны үтәү

мәҗбүри;

– лицензияләүче органнар – Татарстан Республикасы законнары нигезендә лицензияләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары;

– лицензиат – эшчәнлекнең билгеле бер төрен башкару өчен лицензиясе булган юридик зат яисә индивидуаль эшкуар;

– лицензия алырга теләүче – эшчәнлекнең билгеле бер төрен башкару өчен үзенә лицензия бирүләрен сорап лицензияләүче органга мөрәҗәгать итүче юридик зат яисә индивидуаль эшкуар;

– лицензияләр реестры – бирелгән, теркәлгән, туктатып торылган, юкка чыгарылган лицензияләр турындагы белешмәләр бергәлеген тәшкил итүче документ;

– лицензиатларның лицензия таләпләрен һәм шартларын үтәүләрен күзәтеп тору – эшчәнлекнең лицензияләнүче төрләрен башкарганда лицензиатлар тарафыннан тиешле лицензия таләпләре һәм шартлары үтәлешен тәэмин итү максатларында лицензияләүче органнарның, дәүләт күзәтү һәм тикшереп тору органнарының үз вәкаләтләре чикләрендә башкарылучы гамәлләр системасы.

2 статья. **Татарстан Республикасында лицензияләү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында лицензияләү өлкәсендәге мөнәсәбәтләр әлеге Закон, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлар белән җайга салына.

3 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу чикләре**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары тарафыннан Татарстан Республикасы законнары нигезендә башкарылучы эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләүгә кагыла.

Әлеге Законның гамәлдә булуы лицензияләү үзенчәлекләре Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән эшчәнлекнең бүтән төрләрен лицензияләүгә кагылмый.

4 статья. **Лицензияләүне башкаруның төп принциплары**

Лицензияләүне башкаруның төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гражданнарның ирекләрен, хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен, әхлагын, гомерен һәм сәламәтлеген яклаудан;

шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең мәнфәгатьләре бергәлегеннән;

лицензияләгәндә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының барысы өчен дә шартлар тигезлегеннән;

лицензияләүнең хәбәрдарлыгыннан һәм һәркем өчен дә ачык булуыннан;

лицензияләүне башкарганда законлылыкны үтәүдән;

эшчәнлекнең төп төрен тәэмин итүче технологик процесслар бергәлеге нигезендә юридик затларның җитештерү эшчәнлеген лицензияләүдән.

5 статья. **Эшчәнлекнең лицензияләнүче төрләрен билгеләү критерийлары**

Гражданнарның хокукларына, законлы мәнфәгатьләренә, әхлагына, гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерерлек һәм лицензияләүдән тыш башка ысуллар белән җайга салып булмый торган эшчәнлек төрләре лицензияләнүче эшчәнлек төрләренә керә.

6 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының лицензияләү өлкәсендәге вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

Татарстан Республикасында лицензияләү өлкәсендәге эшчәнлекне тәэмин итү буенча комплекслы гамәлләр башкара;

Татарстан Республикасында лицензияләү эшчәнлеген алып бару тәртибен раслый;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең әлеге Законның 7 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы органнарын билгели;

эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәләрне раслый, шул исәптән аларда лицензияләнүче эшчәнлек төрләрен тәшкил итүче эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең исемлеген билгели;

лицензия җыемнарының күләмен билгели һәм аларны түләү буенча законнар нигезендә өстенлекле ташламалар бирә.

7 статья. **Лицензияләүче органнарның вәкаләтләре**

Лицензияләүче органнар түбәндәге вәкаләтләрне

гамәлгә ашыралар:

Татарстан Республикасы территориясендә әлеге Закон, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлар нигезендә лицензияләүне;

лицензияләү таләпләренең һәм шартларының лицензиатлар тарафыннан үтәлешен күзәтүне;

лицензияләрнең гамәлдә булуын туктатып тору;

лицензияләрнең гамәлдә булуын яңарту;

лицензияләрнең барлыгын раслаучы документларны яңадан рәсмиләштерү;

лицензияләр реестрын төзү һәм алып бару.

8 статья. **Лицензияләү өлкәсендә килешүләр**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты дәүләт хакимиятенең федераль органнары белән лицензияләү өлкәсендә үзара вәкаләтләр алмашу турында законнар нигезендә килешүләр төзергә хокуклы.

## 2 бүлек. Лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләре

9 статья. **Эшчәнлекнең лицензия таләп итүче төрләре исемлеге**

Эшчәнлекнең лицензия таләп итүче төрләренә түбәндәгеләр керә:

1) билгеләнгән тәртиптә акцизлар салына торган азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларны күпләп һәм ваклап сату (акцизлар салынган товарларның һәр төркеме буенча);

2) азык-төлек товарларын күпләп һәм ваклап сату;

3) азык-төлек булмаган товарларны күпләп һәм ваклап сату;

4) азык-төлек товарларын җитештерү;

5) казинолар, тотализаторлар һәм башка уен йортларын оештыру һәм тоту;

6) җирле лотереяләр оештыру һәм уздыру;

7) реклама эшчәнлеге;

8) туристлык, шул исәптән халыкара туристлык эшчәнлеге;

9) автотранспорт чараларының түләүле тукталып тору урыннарын, аларны саклауны һәм килеп туктау урыннарына урнаштыруны оештыру;

10) ломбардлар эшчәнлеге;

11) затлы җәнлек тиреләреннән, сарык тиреләреннән һәм күннән чимал әзерләү һәм сату;

12) кара һәм төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю, эшкәртү, сату һәм Татарстан Республикасыннан читкә чыгару;

13) барлар, төнге клублар һәм дискотекалар тоту;

14) кыргый дару үләннәрен җыю һәм аларның чималын сату (Россиянең Кызыл китабына кертелгәннәрдән гайре);

15) медицина эшчәнлеге;

16) фармацевтика эшчәнлеге;

17) риэлтер эшчәнлеге;

18) халыкны эш белән тәэмин итүдә дәүләткә карамаган оешмалар тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтү (Эш белән тәэмин итүнең федераль хезмәте органнары бәяләмәсе булганда);

19) ветеринария эшчәнлеге;

20) ионлы нурландыру (генерацияле) чыганакларына бәйле эшчәнлек;

21) дезинфекцияләү, дезинсекцияләү һәм дератизацияләү чараларын җитештерү;

22) дезинфекцияләү, дезинсекцияләү һәм дератизацияләү эшләрен уздыру эшчәнлеге;

23) инфекция авыруларын кузгатучыларны куллануга бәйле эшчәнлек;

24) мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп (тулы булмаган урта) һәм гомуми (тулы) урта, башлангыч һөнәр, урта һөнәр белеме өлкәсендә мәгариф эшчәнлеге;

25) җир ресурсларын өйрәнүгә һәм файдалануга бәйле җир төзелеше эшләрен һәм башка проект-эзләнү эшләрен башкару;

26) мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау, реставрацияләү һәм файдалану өлкәсендә эшчәнлек;

27) төзелеш өчен проектлау, төзү-монтаж эшләрен һәм инженерлык эзләнүләрен башкару, төзелеш конструкцияләрен һәм детальләрен җитештерү;

28) экологик паспортлаштыруны, сертификацияләүне, экологик аудитлаштыруны уздыру;

29) табигатьне саклау эшләре (хезмәт күрсәтүләре) белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

30) аудио-,кино– һәм видеопродукцияләрне ишәйтү,

сату, прокатка һәм арендага бирү, халыкка күрсәтү, видео-, аудиотека һәм прокат пунктлары аша тарату;

31) җир асты байлыкларыннан файдалану;

32) нефтьне һәм аның эшкәртелмә продуктларын саклау;

33) нефть продуктларын сату;

34) өске сулардан файдалану;

35) аучылык ресурсларыннан файдалану;

36) сәнәгатьтә балыкчылык һәм балык үрчетү;

37) нәселле хайваннар үрчетү, нәселле продукция җитештерү һәм алардан файдалану;

38) җитештерү һәм куллану калдыкларын җыюга, ташуга, саклауга, файдалы эшкә тотуга, зарарсызландыруга, күмүгә бәйле эшчәнлек;

39) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлек;

40)иминият компанияләре тарафыннан медицина иминләштерүен гамәлгә ашыру;

41) медицина техникасын җитештерү, сату һәм аларга техник хезмәт күрсәтү;

42) дәүләткә карамаган пенсия фондлары эшчәнлеге;

43) халыкка социаль хезмәт күрсәтү эшчәнлеге;

44) элемтә хезмәте күрсәтү, элемтә корылмаларын һәм чараларын проектлаштыру, төзү һәм техник эксплуатацияләү;

45) бәяләү эшчәнлеге;

46) хосусый детектив һәм саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

Татарстан Республикасында федераль законнар нигезендә башкарылучы эшчәнлекнең бүтән төрләрен лицензияләү күрсәтелгән законнарга таянып гамәлгә ашырыла.

Әлеге Законда һәм федераль законнарда каралмаган эшчәнлек төрләрен лицензияләү рөхсәт ителми.

## 3 бүлек. Лицензияләү системасы

10 статья. **Лицензия бирү тәртибе**

Лицензия алырга теләүче тарафыннан лицензия алу өчен лицензияләүче тиешле органга түбәндәгеләр тапшырыла:

1) лицензия сорап язылган гариза, анда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

юридик зат өчен — аның тулы исеме һәм оештыру-хокукый рәвеше, юридик адресы, аңа хезмәт күрсәтүче банк исеме һәм банктагы исәп-хисап счетының номеры;

индивидуаль эшкуар өчен — фамилиясе, исеме, атасының исеме, гражданның шәхесен раслаучы документ белешмәләре;

юридик зат яисә индивидуаль эшкуар башкарырга ниятләгән эшчәнлекнең лицензияләнүче төре һәм эшчәнлекнең күрсәтелгән төрен башкару чоры;

2) юридик зат өчен — гамәлгә кую документларының күчермәләре һәм юридик затның дәүләт тарафыннан теркәлүе турындагы таныклык күчермәсе, әгәр күчермәләр нотариус тарафыннан таныкланмаган булса, аларның төп нөсхәләре;

индивидуаль эшкуар өчен — гражданның дәүләт тарафыннан теркәлүе турындагы таныклык күчермәсе, әгәр күчермә нотариус тарафыннан таныкланмаган булса, аның төп нөсхәсе;

3) лицензиатның салым органында исәпкә куелуы турындагы документ;

4) лицензия җыемын түләүне раслаучы документ;

5) эшчәнлекнең билгеле бер төрен үзенчәлегенә карап лицензияләү турындагы нигезләмәдә каралган башка документлар.

Әлеге Законда һәм эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә каралмаган документларны лицензия алырга теләүчедән таләп итү рөхсәт ителми.

Лицензия алу өчен лицензия алырга теләүче тапшырган барлык документлар лицензияләүче орган тарафыннан язып алына, аның күчермәсе, документларны кабул итеп алган көнен күрсәтеп, лицензия алырга теләүчегә җибәрелә (тапшырыла).

Дөреслеккә туры килми торган яисә үзгәртеп күрсәтелгән белешмәләр биргән өчен лицензия алырга теләүче законнар нигезендә җаваплы була.

Лицензияләүче орган эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә торган вакытта, әмма лицензия алу өчен кирәкле барлык документлар белән бергә гариза алынган көннән 15 көннән дә соңга калмыйча, бирелгән документларга һәм эшчәнлекнең билгеле бер төрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартларның булу-булмавына, аларның әлеге Закон һәм эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмә таләпләренә туры килү-килмәвенә экспертиза ясый, шуннан соң лицензия

биру яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Өстәмә, шул исәптән лицензиат таләбе буенча бәйсез экспертиза уткәрү кирәк булган очракта, карар эксперт бәяләмәсе алганнан соң 7 көн эчендә кабул ителә. Бу очракта лицензия биру яисә бирүдән баш тарту турындагы карарны кабул иту вакыты лицензияләүче орган җитәкчесе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма бу вакыт 15 көннән дә артмаска тиеш. Бәйсез экспертиза лицензия алырга теләүче исәбеннән уткәрелә.

Лицензияләүче орган лицензия алырга теләүчегә лицензия биру яисә аңардан баш тарту турында карар кабул иткәннән соң өч көн эчендә лицензия алырга теләүчегә бу хакта хәбәр итә.

Лицензия биру турындагы хәбәр лицензия алырга теләүчегә язма рәвештә җибәрелә (тапшырыла).

Лицензия бирүдән баш тарту турындагы хәбәр, баш тарту сәбәпләре курсәтелгән килеш, лицензия алырга теләүчегә язма рәвештә җибәрелә (тапшырыла).

Түбәндәгеләр лицензия бирүдән баш тарту өчен нигез була:

лицензия алырга теләүче тарафыннан бирелгән документларда дөреслеккә туры килми торган яисә үзгәртеп күрсәтелгән белешмәләр булу;

лицензия алырга теләүченең эшчәнлекнең тиешле төрен башкару өчен кирәкле шартлары булмавын билгеләү турында экспертның тискәре бәяләмәсе булу;

лицензия алырга теләүченең эшчәнлекнең тиешле төрен башкару өчен кирәкле шартлары булу-булмавына экспертиза уздырудан баш тартуы;

лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә һәм шартларына туры килмәве;

лицензия алырга теләүчене – индивидуаль эшкуарны аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан суд карары нигезендә мәхрүм иту.

Лицензия алырга теләүче лицензияләүче органның үзенә лицензия бирүдән баш тартуы яисә бернинди гамәл кылмавы турында законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Лицензияләүче органның лицензия бирүдән баш тартуына карата лицензия алырга теләүче административ тәртиптә шикаять

белдергәндә лицензия алырга теләүче бәйсез экспертиза уткәрүне таләп итәргә хокуклы. Бәйсез экспертиза уткәрү һәм аның өчен түләү тәртибе эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәләрдә билгеләнә.

Эшчәнлекнең әлеге Законда каралган һәр төренә аерым лицензия бирелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә технология процессларының бердәйлеген тәэмин иту максатларында, берничә эшчәнлек төренә бер генераль лицензия бирелергә мөмкин.

Лицензиатның лицензияне башка юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга бирүе тыела.

Лицензияләүче орган тарафыннан бирелгән лицензия Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлдә була.

11 статья. **Лицензия җыемы**

Лицензия биргән өчен лицензия җыемы алына.

Лицензия җыемының максималь күләме хезмәт өчен түләүнең законнарда билгеләнгән 10 минималь күләменнән артмаска тиеш.

12 статья. **Лицензия**

Лицензиядә түбәндәге реквизитлар була:

теркәү номеры;

бирелгән көне;

лицензия биргән органның исеме;

башкару лицензия бирелгән эшчәнлек төре (төрләре);

юридик затның исеме һәм юридик адресы яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен раслаучы документының белешмәләре;

лицензиянең гамәлдә булуының башлану һәм тәмамлану вакытлары;

эшчәнлекнең лицензиядә күрсәтелгән төрен башкару шартлары.

Лицензиядә Татарстан Республикасы законнарында каралган башка белешмәләр дә булырга мөмкин. Лицензия бланклары тиешле дәрәҗәдә якланганлыкка ия булырга тиеш, алар катгый хисап документы булалар, аларның исәпкә алу сериясе һәм номеры була. Лицензия бланкларын алуны, аларны исәпкә алуны һәм саклауны лицензияләүче органнар

башкара.

Лицензиянең үрнәк бланкы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

13 статья. **Лицензиянең гамәлдә булу вакыты**

Лицензиянең гамәлдә булу вакыты әлеге төр эшчәнлекнең үзенчәлегенә бәйле рәвештә эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә, әмма ул өч елдан артмаска тиеш. Законнарда һәм эшчәнлекнең билгеле бер төрләрен лицензияләү турындагы нигезләмәләрдә лицензиянең гамәлдә булу чорын чикләмәү дә каралырга мөмкин.

Лицензия өч елдан азракка бары тик лицензия алырга теләүче гаризасы буенча гына бирелә.

Лицензиянең гамәлдә булу чоры, әгәр эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә башкача каралмаган булса, лицензиат гаризасы буенча озайтылырга мөмкин.

Лицензия гамәлдә булган чорда лицензия таләпләрен һәм шартларын бозулар ачыкланса, лицензиянең гамәлдә булу чорын озайтудан баш тартырга мөмкин.

14 статья. **Лицензияләү таләпләре һәм шартлары**

Лицензиатлар эшчәнлекнең лицензияләнүче төрләрен башкарганда мәҗбүри үтәлергә тиешле лицензия таләпләренең һәм шартларының берсе – Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарны, экологик, санитар-эпидемиологик, гигиеник, янгынга каршы нормаларны һәм кагыйдәләрне, шулай ук эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәләрне үтәү.

Башкару өчен махсус белемнәр таләп итә торган лицензияләнүче эшчәнлек төрләренә карата лицензия таләпләренә һәм шартларына лицензия алырга теләүче һәм лицензиат өчен өстәмә рәвештә квалификацион таләпләр, аерым алганда, юридик затның хезмәткәрләре яисә индивидуаль эшкуар булган граждан өчен квалификацион таләпләр куелырга мөмкин.

Башкару өчен махсус шартлар таләп итә торган лицензияләнүче эшчәнлек төрләренә карата өстәмә рәвештә лицензия таләпләренә һәм шартларына үзендә билгеле бер эшчәнлек төре башкарыла торган объектның яисә үзен

кулланып эшчәнлек башкарыла торган объектның күрсәтелгән махсус шартларга туры килүе турындагы таләпләр куелырга мөмкин.

Эшчәнлекнең лицензияләнүче төренә карата өстәмә лицензияләү таләпләре һәм шартлары исемлеге эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә.

15 статья. **Лицензияне яңадан рәсмиләштерү һәм теркәү**

Юридик затны үзгәртеп корганда, аның исеме яисә урнашкан урыны үзгәргәндә лицензиат – юридик зат яисә аның хокук дәвамчысы лицензия булуны раслаучы документны яңадан рәсмиләштерү турында кичекмәстән гариза бирергә тиеш, күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы тиешле документлар кушып бирелә.

Индивидуаль эшкуарның исеме яисә яшәү урыны үзгәргәндә лицензиат – индивидуаль эшкуар лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында кичекмәстән гариза бирергә тиеш, күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы тиешле документлар кушып бирелә.

Лицензияне яңадан рәсмиләштергәндә лицензияләүче орган лицензияләр реестрына тиешле үзгәрешләр кертә. Лицензияне яңадан рәсмиләштерү лицензиат тиешле гариза биргән көннән биш көн эчендә башкарыла.

Лицензиянең булуын раслаучы документны яңадан рәсмиләштергән очракта, әлеге документны биргән һәм аңа үзгәрешләр керткән өчен түләү алына. Әлеге түләүнең күләме Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм ул хезмәт өчен түләүнең законнарда билгеләнгән минималь күләменең уннан бер өлешеннән югарырак була алмый.

16 статья. **Лицензияләүче органнарга лицензиатның хәбәр итүе**

Юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең лицензияләү эшчәнлеген алып барырга вәкаләтле органнары тарафыннан федераль законнар нигезендә бирелгән лицензия буенча Татарстан Республикасы территориясендә алып барыла торган эшчәнлеге лицензиат бу хакта эшчәнлекнең тиешле

төрен лицензияләүче органнарга хәбәр иткәннән соң башкарыла, хәбәр иткән өчен җыем алынмый.

**17 статья. Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору һәм аны юкка чыгару**

Лицензияләүче органнар лицензиянең гамәлдә булуын түбәндәге очракларда туктатып тора алалар:

лицензияләүче органнар, дәүләт күзәтеп тору һәм тикшереп тору органнары, дәүләт хакимиятенең башка органнары лицензиат тарафыннан лицензия таләпләре һәм шартлары гражданнарның хокукларына, законлы мәнфәгатьләренә, әхлагына, гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерерлек итеп бозылуын үз компетенцияләре чикләрендә ачыклаганда;

лицензияләү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтүен башкаручы органнарның карарларын лицензиат үтәмәгәндә.

Юридик зат юкка чыгарылган яисә үзгәртеп оештыру аркасында үз эшчәнлеген туктаткан мизгелдән, моңа аның үзгәртеп корылуы керми, шулай ук гражданны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның гамәлдә булуы туктатылган очракта лицензия юридик көчен югалта һәм ул юкка чыгарылган дип санала.

Лицензия аны бирүче лицензияләүче органның яисә үз компетенциясе нигезендә дәүләт хакимияте органының гаризасы нигезендә суд карары белән юкка чыгарыла. Судка гариза бирү белән бер үк вакытта лицензияләүче орган күрсәтелгән лицензиянең гамәлдә булуын суд карары үз көченә кергән чорга кадәр туктатып торырга хокуклы.

Түбәндәгеләр лицензияне юкка чыгару өчен нигез була:

лицензия алу өчен тәкъдим ителгән документларда дөреслеккә туры килмәгән яисә үзгәртеп күрсәтелгән белешмәләр ачыклану;

лицензиатның лицензия таләпләрен һәм шартларын берничә мәртәбә яисә тупас бозуы;

лицензия бирү турындагы карарның законсызлыгы;

лицензиатның тиешле гариза бирүе.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы яисә лицензияне юкка чыгару хакындагы гаризаны судка җибәрү турындагы карарны лицензияләүче орган, карар кабул

ителгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча, дәлилле нигезләве белән бергә, язма рәвештә лицензиатка җиткерә.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы карарга карата законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

Лицензияләүче орган лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләрнең лицензиат тарафыннан бетерелү вакытын билгеләргә тиеш. Бу вакыт алты айдан да артмаска тиеш. Әгәр билгеләнгән вакыт эчендә лицензиат күрсәтелгән хәлләрне бетермәсә, лицензияләүче орган лицензияне юкка чыгару турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Лицензиат лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләрне бетергән очракта, лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торучы лицензияләүче орган аның гамәлдә булуын яңарту турында карар кабул итәргә тиеш.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләрнең лицензиат тарафыннан бетерелүен раслау тәртибе, аның гамәлдә булуын яңарту турында лицензияләүче орган тарафыннан карар кабул итү вакытлары эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә.

18 статья. **Лицензияләрнең реестрларын оештыру һәм алып бару**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты лицензияләүче органны билгели, ул әлеге Закон нигезендә лицензияләүне гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан бирелгән, теркәлгән, туктатып торылган һәм юкка чыгарылган лицензияләрнең бердәм республика реестрын шушы органнар тарафыннан бирелүче белешмәләр нигезендә оештыра һәм алып бара.

Лицензияләүче органнар үзләре биргән, теркәгән, туктатып торган һәм юкка чыгарган лицензияләрнең реестрын оештыралар һәм алып баралар.

Лицензияләрнең реестрында түбәндәге белешмәләр була:

1) лицензия биргән лицензияләүче орган турында белешмәләр;

2) лицензиатлар турында белешмәләр;

3) башкару өчен лицензия бирелгән эшчәнлек төрләре;

4) лицензияне бирү яисә теркәү көне һәм лицензия номеры;

5) лицензиянең гамәлдә булуының башлану һәм тәмамлану вакытлары;

6) лицензия шартлары;

7) лицензияләрне реестрларда теркәү турындагы белешмәләр, лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору һәм яңарту, лицензияне юкка чыгару нигезләре һәм көннәре;

8) лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында белешмәләр;

9) эшчәнлекнең билгеле бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәләрдә билгеләнгән бүтән белешмәләр.

Лицензияләүче органнар лицензияләр реестрыннан дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына бушлай мәгълүматлар бирергә тиеш.

Лицензияләр реестрларыннан мәгълүмат бирү вакыты тиешле гариза бирелгән көннән соң өч көннән дә артмаска тиеш.

### 19 статья. **Лицензияләү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуы һәм күзәтүе**

Лицензиатның лицензия шартларын үтәвен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны һәм күзәтүне лицензияне биргән яисә теркәгән орган, шулай ук шуңа вәкаләт бирелгән дәүләт тикшереп тору һәм күзәтү органнары законнар нигезендә гамәлгә ашыралар.

Лицензияләү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтүен гамәлгә ашыручы органнар үз компетенцияләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

лицензиатның лицензияләү өлкәсендәге законнарның таләпләрен һәм лицензия шартларын үтәвен тикшереп торырга;

законнарда билгеләнгән белешмәләрдән гайре, тикшерү барышында килеп чыгучы мәсьәләләр буенча лицензиатлардан кирәкле аңлатмалар, белешмәләр һәм мәгълүматлар алырга;

лицензияләү өлкәсендә хокук бозуларны бетерү турында үтәлеше мәҗбүри булган (конкрет хокук бозулар һәм аларны бетерү вакытлары күрсәтелгән) күрсәтмәләр (тәкъдимнәр) бирергә;

лицензияне биргән яисә теркәгән органга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору яисә аны юкка чыгару турында тәкъдим кертергә;

гаепле затларны законнарда билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тартырга, аларны дисциплинар,

административ яисә җинаять җаваплылыгына тарту турында судка материаллар җибәрергә, дәгъвалар кертергә.

Лицензияләү өлкәсендә хокук бозулар ачылганда, тикшереп һәм күзәтеп торучы дәүләт органнары, шулай ук дәүләт хакимиятенең бүтән органнары лицензия биргән яисә теркәгән органга ачылган хокук бозулар һәм күрелгән чаралар турында хәбәр итәләр.

Лицензияләү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтүен гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан тикшерү уздыру өчен лицензиат эшчәнлекнең аерым бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмә нигезендә кирәкле белешмәләр һәм документлар бирергә, шулай ук шартлар тәэмин итәргә тиеш.

Лицензиат, күрсәтмәдә (тәкъдимдә) билгеләнгән вакыт узгач, күрсәтмә (тәкъдим) биргән органга һәм лицензия биргән органга тикшерү барышында ачылган хокук бозуларны бетерү турында белешмәләр бирергә тиеш.

Лицензияләү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын гамәлгә ашыру тәртибе эшчәнлекнең аерым бер төрен лицензияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнә.

Лицензияләү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтүен башкаручы органнарның һәм аларның урындагы затларының гамәлләренә (карарларына) карата судка шикаять белдерелергә мөмкин.

## 4 БҮЛЕК. ЙОМГАК НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 20 статья. Лицензияләү эшчәнлеген финанслау

Лицензияләү эшчәнлеген финанслау лицензияләүче органнарны тотуга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан бүлеп бирелүче акчалар исәбеннән башкарыла.

### 21 статья. Лицензияләү турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

Лицензияләүче органнарның урындагы затлары әлеге Законның һәм лицензияләү өлкәсендә башка норматив-хокукый актларның таләпләрен бозган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

Лицензияләнергә тиешле эшчәнлекне лицензиясез яисә лицензия шартларын бозып башкаручы юридик затлар һәм

индивидуаль эшкуарлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

22 статья. **Лицензияләүдән керүче акчаларны бүлү**

Лицензияләүче территория органнары лицензияләвеннән керүче акчалар җирле бюджетларга җибәрелә.

Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары лицензияләвеннән керүче акчалар Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2054

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 482. "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законын басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

2. Эшчәнлекнең аерым төрләрен башкаруга әлеге Законны гамәлгә керткәнче билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензияләр аларда куелган вакытлар беткәнчегә кадәр гамәлдә булалар.

3. Эшчәнлекнең шушы Закон белән яңа билгеләнгән аерым төрләренә лицензия алырга теләүчеләр "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә керткән көннән башлап 6 ай эчендә лицензияләүче органнарга лицензияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрсәтелгән Закон басылып чыккан көннән өч ай эчендә:

- Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив-хокукый актларын "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законына туры китерергә;

- "Лицензияләү турында" Татарстан Республикасы Законыннан килеп чыга торган тиешле норматив-хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1998 елның 3 июлендәге 1700 номерлы "Лицензияләү турында" Татарстан

Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында"гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 24 марты
№ 2055

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 483. Югославия Союз Республикасындагы сугыш вакыйгалары белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Югославия Союз Республикасындагы сугыш вакыйгалары белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белдерүен кабул итәргә.

2. Әлеге Белдерүне Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Премьер-министрына, Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына һәм Федерация Советына, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарына, Татарстан Республикасының чит илләрдәге вәкиллекләренә, халыкара оешмаларга, Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 апреле
№ 2060

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 484. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 28 апрелендәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 28 апрелендәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. "Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

2. "Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

3. "Торак сатып алуда яисә торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. Татарстан Республикасының Су кодексы проекты турында.

5. "Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

7. "Татарстан Республикасы референдумы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

8. "Татарстан Республикасында товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сертификацияләү турында" Татарстан Республикасы законы хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

9. "Татарстан Республикасының Мөслим районы Симәк җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Крынтау торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

10. Голландия банкы биргән 100 млн. АКШ доллары суммасында кредиттан файдалану турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы.

11. Татарстан Республикасы Конституциясенең 86 статьясын һәм "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларының статусы турында"

Татарстан Республикасы Законының 25 статьсын Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатлары качылгысызлыгын тәэмин итү һәм депутат эшчәнлегенең гарантияләре өлешендә Татарстан Республикасы Прокуратурасының үтәве хакында.

12. Татарстан Республикасында балаларны гепатитка каршы вакциналаштыру турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматы.

13. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2091

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 485. "Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. "Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. "Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында" Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2092

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 486. Татарстан Республикасының Су кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасының Су кодексы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Су кодексы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дәрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый байлыклар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2093

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 487. "Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Экологик экспертиза турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларын бетерү, статьяларының үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый ресурслар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2094

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 488. "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдидмнәрне, искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 12 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе күрсәтелгән закон проектын, кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, 1999 елның 21 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм икенче укылышка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2095

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 489. "Татарстан Республикасы референдумы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:** "Татарстан Республикасы референдумы турында"

Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" 1997 елның 16 октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән һәм Татарстан Республикасы Президенты кире кайтарган Татарстан Республикасы законын, Килештерү комиссиясенең тәкъдимен исәпкә алып, караудан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2096

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 490. "Татарстан Республикасында товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сертификацияләү турында" Татарстан Республикасы законы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

"Татарстан Республикасында товарларны (эшләрне, хезмәт крсәтүләрне) сертификацияләү турында" 1997 елның 18 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән һәм Татарстан Республикасы Президенты кире кайтарган Татарстан Республикасы законын, Килештерү комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып,караудан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2097

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 491. 1999 ел навигациясе башында "Татфлот" суднолар йөртү компаниясенең ягулык белән җитәрлек тәэмин ителмәве сәбәпле канәгатьләнерлек эшләмәве турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы хакында

1999 ел навигациясе башында "Татфлот" суднолар йөртү компаниясенең ягулык белән җитәрлек тәэмин ителмәве сәбәпле канәгатьләнерлек эшләмәве турында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.А.Швецов мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1999 ел навигациясе башында "Татфлот" суднолар йөртү компаниясенең ягулык белән җитәрлек тәэмин ителмәве сәбәпле канәгатьләнерлек эшләмәве турында мәгълүматны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2098

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 492. Казан-Чаллы юлының торышын яхшырту һәм анда травмаларын киметү чаралары турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы турында

Казан-Чаллы юлының торышын яхшырту чаралары турында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.А.Швецовның һәм анда травмалар алуны киметү чаралары турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш травматологы һәм ортопеды Х.З.Гафаров мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.А.Швецов һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш травматологы һәм ортопеды Х.З.Гафаров мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты ике ай эчендә 1999-2000 елларга Казан-Чаллы автомобиль юлын техник җиһазлау, юл хәрәкәтендә катнашучыларга сервис хезмәте күрсәтү һәм зыян күрүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү буенча өстәмә чаралар расларга тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2099

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 493. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законының 16 статьясының үтәлмәве хакында" Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе турында

Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбе буенча Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары В.Г.Метелин мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законының 16 статьясының үтәлмәве хакында" Татарстан Республикасы халык депутаты С.К.Осколок таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 апреле
№ 2100

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 494. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясен 1999 елның 26 маенда Казан шәһәрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2065

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 495. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Аерым сайлау округлары буенча Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматы.
2. “Татарстан Республикасының бюджеттан тыш

дәүләт фондлары турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. "Иминлек турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

6. 1999-2000 елларга "Татарстан яшьләре" Дәүләт программасы проекты турында.

7. "Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. "Уен бизнесына салым турында" 1998 елның 31 июлендәге 142-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасы территориясендә куллану хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

9. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кайбер даими комиссияләре составындагы үзгәрешләр турында.

10. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

11. Татар телендә телерадиотапшыруларны саклап калу һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте күрә торган чаралар турында.

12. 2000 елга кадәр Татар милли университетын ачу өлешендә "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәүнең барышы хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның 22 маендагы 1174 нче карарын үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте мәгълүматы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2066

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
## КАРАРЫ

### 496. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы язгы сессиясенең чираттагы утырышын 1999 елның 28 апрелендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2067

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
## КАРАРЫ

### 497. 1999 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1."Хәйрия эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

2."Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3."Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4."Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5.“Торак сатып алуда яисә торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6.“Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7.Татарстан Республикасы Су кодексы проекты турында.

8.“Экологик экспертиза турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9.“Ана даны” Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10.“Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

11.“Алабуга” ирекле икътисадый зонасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

12.“Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

13.“Татарстан Республикасы референдумы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

14.“Татарстан Республикасында товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сертификацияләү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

15.“Татарстан Республикасының Мөслим районы Симәк җирле үзидарәсе территориясендә яңа барлыкка килгән Крынтау торак пунктын теркәү һәм аңа исем бирү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2068

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 498. 1999 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1.“Хәйрия эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

2. “Кама Аланы” махсус икътисадый зонасы турында” Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3.“Торак сатып алуда яисә торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

4.“Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

5. Татарстан Республикасы Су кодексы проектын эшләүне дәвам итү турында.

6. “Экологик экспертиза турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

7. “Ана даны” Татарстан Республикасы медален гамәлгә кую турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

8. “Татарстан Республикасында дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

9.“Алабуга” иректә икътисадый зонасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

10.“Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында”

Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2069

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 499. 1999 елның II кварталына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эшен оештыру чаралары планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның II кварталына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эшен оештыру чаралары планын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2070

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 500. “Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясына өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясе карарын исәпкә алып, “Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясына өстәмәләр кертү турында”

Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2079

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 501. "Туфракның уңдырышлылыгы турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Экологик иминлек мәсьәләләре, табигый ресурслар һәм табигатьтән файдалану комиссиясенең 1999 елның 18 мартындагы 74 нче карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәсе нигезендә эшләп бетерү өчен "Туфракның уңдырышлылыгы турында" Татарстан Республикасы законы проектын закон проекты инициаторына кайтарып бирергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2080

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
## КАРАРЫ

### 502. “Татарстан Республикасында исемле хосусыйлаштыру исәпләре (кертемнәре) турында” Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен аңлату хакында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы халык депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы А.В.Семин мөрәҗәгатен исәпкә алып, “Татарстан Республикасында исемле хосусыйлаштыру исәпләре (кертемнәре) турында” Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен аңлату хакында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2081

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
## КАРАРЫ

### 503. 1999 елда Татарстан Республикасы халык депутатлары җирле Советлары эше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1998 елда Татарстан Республикасы халык депутатлары җирле Советлары эше турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2082

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
## КАРАРЫ

### 504. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында булган тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чаралары планын расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2083

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
## КАРАРЫ

### 505. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 11 мартындагы XVIII пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тәкъдимнәре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 11 мартындагы XVIII пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары Министрлар кабинеты адресына әйткән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә.

Бер айдан да соңга калмыйча карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

2. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2084

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 506. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 24 мартындагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары әйткән тәкъдимнәр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 24 мартындагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы һәм даими комиссияләре адресына әйткән тәкъдимнәрне үтәү чаралары планын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 24 мартындагы утырышында Татарстан Республикасы халык депутатлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына әйткән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә (2 нче кушымта).

3. Чаралар планын үтәү һәм тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 апреле
№ 2085

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 507. Татарстан Республикасы Питрәч район хакимияте башлыгы карарын юкка чыгару турында

Татарстан Республикасы Питрәч район хакимияте башлыгының "Яңа хуҗалык субъектларын теркәү турында"гы 1999 елның 10 мартындагы 96 нчы карары нигезендә яңа төзелә торган хуҗалык субъектларын дәүләт тарафыннан теркәү өчен мәҗбүри рәвештә район хакимияте башлыгыннан рөхсәт алу тәртибе кертелде. Әлеге карар Татарстан Республикасы Конституциясенең 10 статьясын, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасында юридик затларны дәүләт тарафыннан теркәүнең бердәм системасын төзү чаралары турында"гы 1998 елның 4 мартындагы 171 нче Указы таләпләрен бозып чыгарылган.

Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык эшчәнлеге алып бару ирекен тәэмин итү, хуҗалык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче субъектларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен чикләүгә юл куймау, кәсәбәчелекне үстерүдә артык мәшәкатьләр һәм бюрократик киртәләр тудырмау, Татарстан Республикасы территориясендә юридик затларны һәм аерым кәсәбәчеләрне дәүләт тарафыннан теркәүнең бердәм тәртибен саклау максатында һәм Татарстан Республикасы Конституциясендәге 111 статьяның 12 пункты нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Президенты указларына каршы килгәнгә, Татарстан Республикасы Питрәч район хакимияте башлыгының "Яңа хуҗалык субъектларын теркәү турында"гы 1999 елның 10 мартындагы 96 нчы карарын юкка чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы район һәм шәһәр хакимиятләре башлыкларына юридик затларны һәм аерым кәсәбәчеләрне дәүләт тарафыннан теркәү тәртибен җайга салучы гамәлдәге законнарны бозуга юл куймаска.

3. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 5 апрель
№ УП-255

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 508. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары системасында югары һәм баш административ дәүләт вазифалары буенча квалификация таләпләре турында

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәткәрләренең югары һөнәри дәрәҗәсен,Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары системасында югары һәм баш административ дәүләт вазифалары буенча бердәм квалификация таләпләрен тәэмин итү максатында һәм "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары системасында югары һәм баш административ дәүләт вазифалары буенча түбәндәге квалификация таләпләре билгеләргә:

- югары административ дәүләт вазифалары өчен: югары,кагыйдә буларак һөнәри белем, баш административ дәүләт вазифаларында кимендә 3 ел яки дәүләт хезмәтенә карамаган җитәкче урыннарында кимендә 7 ел эш стажы;
- баш административ дәүләт вазифалары өчен: югары, кагыйдә буларак, һөнәри белем, баш белгеч сыйфатында дәүләт хезмәтендә кимендә 3 ел яки дәүләт хезмәтенә карамаган җитәкче урыннарында кимендә 5 ел эш стажы.

Бу квалификация таләпләре әлеге Указ көченә кергәннән соң Татарстан Республикасында дәүләт хезмәткәрләре биләгән югары һәм баш административ дәүләт вазифаларына карата кулланыла.

2. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары системасында югары һәм баш административ дәүләт вазифаларын биләгән дәүләт хезмәткәрләренең вазифаи ка-

гыйдәләр тупламасы әлеге Указның 1 пунктында билгеләнгән квалификация таләпләре нигезендә тиешле дәүләт органнары җитәкчеләре тарафыннан расланалар һәм теге яки бу вазифаның функциональ үзенчәлекләренә һәм дәүләт органының вәкаләтләренә бәйле рәвештә дәүләт хезмәткәрләренең конкрет хокукларын һәм бурычларын чагылдырырга тиешләр.

3. Дәүләт идарәсе органнары җитәкчеләренә 3 ай эчендә Татарстан Республикасында югары һәм баш административ дәүләт вазифалары буенча вазифаи кагыйдәләр тупламасы әзерләргә һәм расларга.

4. Әлеге Указны гамәлгә ашыруга контрольлек итүне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына йөкләргә.

5. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 19 апрель
№ УП-306

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 509. Татарстан Республикасы промышленность предприятиеләре һәм оешмаларының бурычларын еструктуралаштыру турында

Промышленность предприятиеләре һәм оешмаларының финанс хәлен тотрыклыландыру һәм савыктыру өчен икътисадый шартлар тудыру максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны алга таба өч ел дәвамында түләү шарты белән, түбәндә күрсәтеләчәк бурычларны түләү өчен бер ел вакыт биреп, промышленность предприятиеләре һәм оешмаларының 1999 елның 1 апреленә Татарстан Республикасының республика бюджетына салымнар, җыемнар һәм пенялар, шулай ук салым законнарын бозган өчен билгеләнгән штрафлар буенча бурычларына реструктуралаштыру уздырырга.

Бурычларны түләүне кичектереп тору һәм алга таба аларны бүлеп-бүлеп түләү хокукы шушы билгеләнгән түләү

сроклары дәвамында агымдагы түләүләрне вакытында һәм тулысынча кертеп барган югарыда күрсәтелгән предприятиеләргә һәм оешмаларга бирелә. Алынмый калган керемнәрне шушы ук кварталда түләп бетергәндә, агымдагы түләүләрне кертү вакытын кварталга ике тапкырдан да артыграк бозмаган очракта, реструктуралаштыру хокукы сакланырга мөмкин.

Шушы шартлар үтәлгәндә ел саен предприятиеләрнең һәм оешмаларның 1999 елның 1 апреленә пенялар һәм штрафлар буенча җыелган бурычлар суммасының дүрттән бер өлеше гамәлдән чыгарыла һәм бер үк вакытта соңгы елда бурычны тулысынча түләп бетергәнче чираттагы пенялар һәм штрафлар буенча калган бурычны түләү өчен вакыт бирелә.

Вакытында түләнмәгән һәм кичектереп түләнгән түләүләр суммасыннан елга 5 процент күләмдә түләү алына.

2. Акционерлык җәмгыятьләренә, аларның 1999 елның 1 апреленә Татарстан Республикасының республика бюджетына булган бурычлары суммасы күләмендә җәмгыятьнең гади акцияләре рәвешендәге облигацияләр чыгаруны гамәлгә ашырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән шартларда бурычларны түләү өчен тапшырырга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указның 1 һәм 2 пунктларын гамәлгә ашыру тәртибен эшләргә һәм расларга;

әлеге Указга бәйле рәвештә “1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында закон проекты эшләргә һәм бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә.

Татарстан Республикасы Президентына бу Указның үтәлеше хакында квартал саен мәгълүмат бирергә.

4. Халык депутатларының җирле Советларына, җирле хакимият башлыкларына шушы Указдагы 1 пунктның җирле бюджетларга средстволар кучерүне күздә тоткан өлешенә туры килгән карарлар кабул итәргә.

5. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 19 апрель
№ УП-311

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 510. 1999 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, карар бирәм:

1999 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1. Язучы Әхсән Фәтхелбаян улы Баяновка, "Урланган ай" китабы өчен (Татарстан китап нәшрияты,1997 ел);

2. Композитор Анатолий Борисович Лупповка, Г.Кутуй повесте буенча язган "Тапшырылмаган хатлар" монооперасы һәм Кыллы оркестр өчен "Кара урман" җиденче симфониясе өчен.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 23 апрель
№ УП-355

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ КОМИТЕТЫ БӘЯЛӘМӘСЕ

### 511. "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турындагы күрсәтмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 номерлы карарының Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм гамәлдәге законнарга туры килү-килмәве турында

Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитеты рәислек итүче Ә.Г.Гатауллин, Комитет әгъзалары Б.Л.Железнов, А.В.Косоруков, Р.И.Тарнапольский, Д.Ә.Сафина составында, "Татарстан Республикасында конституциячел күзәтчелек турында" Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына, 11 статьясының 2 өлешенә, шулай ук 16 статьясына таянып, үз инициативасы буенча ачык утырышында "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турындагы күрсәтмәне раслау хакындагы мәсьәләне карады.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинаның, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе рәисе И.С.Абдуллинның, халык депутаты Ю.П.Прохоровның Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитетына мөрәҗәгатьләре һәм шулай ук гражданка В.И.Григорьева һәм башкаларның шикаятьләре бу мәсьәләне карауга сәбәп булды, аларда "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен гаризаларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү турында" Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган күрсәтмәнең һәм шушы Күрсәтмәгә кушып бирелүче һәм "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен нигез булып торучы бүләкләүләр исемлегенең "Ветераннар турында"

Федераль законның 7 статьясы нормаларына туры килмәвенең хокук саклау гамәлиятендә ачыклануы Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитетына җиткерелә.

Комитет әгъзасы – нотыкчы А.В.Косоруковның хәбәрен, шулай ук Татарстан Республикасы халык депутаты Ю.П. Прохоровның һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты белгечләренең аңлатуларын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитеты түбәндәгеләрне **билгеләде**:

1. "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының 1994 елның 15 февралендәге Шартнамәсенең II статьясындагы 1 пункты, III статьясының 15 пункты һәм IV статьясының 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклауны тәэмин итү вәкаләтләренә ия, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагына социаль яклау (моңа социаль тәэминат та керә) өлкәсендә гомуми сәясәт уздыру керә, ә бары тик Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карамагында гына булган предмет Россия Федерациясе социаль үсеш өлкәсендәге федераль сәясәт нигезләрен һәм федераль программаларны билгеләүдән гыйбарәт була.

"Ветераннар турында" Федераль закон преамбуласы Россия Федерациясендә ветераннарга лаеклы тормыш, актив эшчәнлек, җәмгыятьтә абруй һәм хөрмәт тәэмин итүче шартлар булдыру максатларында әлеге Законның аларны яклауның оештыру, икътисадый һәм хокукый нигезләрен билгеләвен күздә тота. Шул ук вакытта "Ветераннар турында" Федераль Законның 11 статьясы эчтәлегеннән Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнарының ветераннар турында законнар һәм башка норматив-хокукый актлар, шул исәптән әлеге Федераль Законны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән актлар чыгаруга хокуклылыгы килеп чыга.

Шул сәбәпле Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 номерлы карарын бастыру һәм аның "Хезмәт ветераны" исемен бирү

өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау тәртибе турында күрсәтмәне раславы хокуклы булып тора һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 59 статьясына, Татарстан Республикасының дәүләтара шартнамәчел бурычларына, федераль законнарның тиешле нормаларына каршы килми. Әлеге норматив актны бастыру Татарстан Республикасының социаль-мәдәни төзелеше мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итү хокукын тормышка ашыра һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 119 статьясының 2 пунктындагы нигезләмәләргә таянып, гомумдәүләт социаль тәэминат сәясәтен тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләтләре чикләреннән чыкмый.

2. "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау тәртибе һәм хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге карары белән расланган күрсәтмә (алга таба – "Күрсәтмә") "Ветераннар турында" Федераль Законның 7 һәм 22 статьялары белән билгеләнгән гражданнарның хезмәт ветераны хокукларын гамәлгә ашыруның оештыру-хокукый шартларын билгеләүче, әлеге Законнан килеп чыгучы норматив-хокукый акт булып тора. Анда "Хезмәт ветераны" исемен дәгъвалаучы затларның, шулай ук Татарстан Республикасының гражданнарның тиешле гаризаларын һәм документларын кабул итү, теркәү һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм тапшыру буенча оештыру эшен башкаруга вәкаләтле органнары гамәлләре тәртибе регламентлана.

Гражданнар тарафыннан үзләренең закон белән билгеләнгән хокукларын гамәлгә ашыру процедурасын җайга салу күзлегеннән караганда, әлеге Күрсәтмә тулаем Россия Федерациясе Президентының 1995 елның 7 маендагы 471 нче Указы белән расланган "Хезмәт ветераны" исеме бирү тәртибе һәм шартлары таләпләренә, шулай ук "Ветераннар турында" Федераль закон белән каралган ветераннарның хокуклары һәм өстенлекле ташламалары гамәлгә ашырылучы таныклыклар турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 27 апрелендәге 423 номерлы карарына каршы килми.

Шул ук вакытта Күрсәтмәдә Татарстан Республикасында

булган дәүләт хакимияте органнары системасының, шул исәптән социаль тәэминат (социаль яклау) органнарының үзенчәлекләрен, шулай ук аларның гражданнар гаризаларын кабул итү, теркәү һәм карау һәм тиешле документларны тутыру буенча моннан килеп чыга торган үзенчәлекләрне исәпкә алган нормалар бар. Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитеты мондый хокукый регламентлаштыру Татарстан Республикасы Конституциясенең 122 статьясы таләпләренә каршы килми, дип саный, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты алар нигезендә Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм аңа буйсынучы башка органнар эшен берләштерергә һәм юнәлтергә хокуклы.

3. "Ветераннар турында" Федераль законның 7 статьясы ("Ветераннар турында" Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү турында" 171-ФЗ номерлы Федераль законның 1998 елның 18 ноябрендәге редакциясендә) "Хезмәт ветераны" исеменең СССР, РСФСР яисә Россия Федерациясе орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән яисә мактаулы исемнәргә лаек булган, яки аерым хезмәт күрсәткән өчен ведомство билгеләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яисә озак еллар нәтиҗәле эшләгән өчен пенсиягә хокук бирүче затлар өчен билгеләнүен күздә тота.

Шуңа бәйле рәвештә югарыда китерелгән норманы дөрес куллану, шулай ук гражданнарга "Хезмәт ветераны" исемен юридик яктан нигезле бирү яисә бирүдән баш тарту өчен Күрсәтмәнең 2 пункты, шулай ук әлеге Күрсәтмәнең "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен нигез булып торучы бүләкләр исемлеге (моннан ары "Бүләкләр исемлеге") принципиаль әһәмияткә ия.

Күрсәтмәнең 2 пунктында, пенсия турындагы законнарда билгеләнгән документлар белән беррәттән, Бүләкләр исемлегендә санап кителгән СССРның, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләренә документларның (СССРның, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәренә таныклыклар) да "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен нигез булуы каралган. Исемлеккә исә аны бастырып чыгарган мизгелдә гамәлдә булган Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре (Россия Федерациясе Герое исеме, Россия Федерациясе орденнары, медаль-

ләре һәм мактаулы исемнәре), СССР дәүләт бүләкләре (Советлар Союзы Герое, Социалистик Хезмәт Герое, "Герой ана" исемнәре, СССР орденнары, медальләре һәм мактаулы исемнәре) кертелгән, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре кертелгән.

"Ветераннар турында" Федераль законның 11 статьясындагы 5 өлешендә ветераннарны социаль яклау буенча әлеге Федераль законда каралмаган өстәмә чаралар турында Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару һәм башкарма хакимияте органнарының үз компетенцияләре һәм үзләренең акчалары чикләрендә карарлар кабул итәргә хокуклы булулары билгеләнә. Шуларны исәпкә алып, Күрсәтмәнең 2 пунтына, шулай ук аңа кушымта итеп бирелүче Бүләкләр исемлегенә "Ветераннар турында" Федераль законның 7 статьясында каралмаган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре кертелүне хезмәт ветераннарын социаль яклау буенча законда билгеләнгән чараларның Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре булган затларга кагылуы турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителгән карар дип карарга кирәк, әлеге чараларның финанслануы, "Ветераннар турында" Федераль законның 10 статьясындагы 3 өлешендә каралганча, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлары акчалары исәбеннән булуы шарт.

Шулар белән бергә, Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитеты Күрсәтмәнең 2 пунктында һәм аңа кушымта итеп бирелүче Бүләкләр исемлегендә җитди җитешсезлекләр һәм кимчелекләр булуын һәм аларның бүгенге көнгә кадәр дәвам итүен билгеләп үтә.

Мәсәлән, Күрсәтмәнең 2 пунктында РСФСРның дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре, шулай ук хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгалары күрсәтелмәгән һәм "Хезмәт ветераны" исемен дәгъвалаучы затлар тарафыннан әлеге бүләкләүне раслаучы документларны тәкъдим итү мөмкинлеге каралмаган.

Шул ук вакытта, Күрсәтмәгә кушымта итеп бирелүче бүләкләр исемлегендә Россия Федерациясе Президентының 1994 елның 2 мартындагы 442 номерлы Указы белән, (Россия Федерациясе Президентының 1999 елның 6 гыйнварендагы 19 номерлы Указы нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр

кертеп), шулай ук Россия Федерациясе Президентының 1995 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы “Россия Федерациясенең мактаулы исемнәрен билгеләү, мактаулы исемнәр турындагы нигезләмәләрне һәм Россия Федерациясенең мактаулы исемнәренә күкрәк тамгасын тасвирлауны раслау турында”гы Указы белән расланган Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре турындагы нигезләмәдә билгеләнгән дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәр тулысынча чагылдырылмый. Анда РСФСРның дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре, хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгалары бөтенләй күрсәтелмәгән.

Шул ук вакытта, “Ветераннар турында” Федераль законның 7 статьясында (“Ветераннар турында” Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү турында” 1998 елның 18 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) СССРның, РСФСРның яисә Россия Федерациясенең орденнары һәм медальләре, йә мактаулы исемнәре, йә хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгалары белән бүләкләнгән затларга “Хезмәт ветераны” исеме бирү һәм шуңа бәйле социаль яклау чаралары күрү өчен турыдан-туры юридик нигезләүләрнең берсе буларак шушы орденнарның һәм медальләрнең йә мактаулы исемнәрнең, йә хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгаларының булуы билгеләнә.

Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитеты, Күрсәтмәнең 2 пунктына һәм аңа кушымта итеп бирелүче Бүләкләр исемлегенә Россия Федерациясенең кайбер дәүләт бүләкләрен һәм мактаулы исемнәрен, РСФСРның кайбер дәүләт бүләкләрен һәм мактаулы исемнәрен, хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгаларын кертмәү “Ветераннар турында” Федераль Законның 11 статьясындагы 4 өлеше таләпләренә дә каршы килә, дип саный. Шулар нигезендә ветераннарның әлеге Федераль Законда каралган хокукларын һәм ташламаларын чикләүче Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка төрле норматив-хокукый актлары гамәлгә яраксыз була.

Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитетына һәм дәүләт хакимиятенең башка органнарына гражданнарның мөрәҗәгать итүе Татарстан Республикасының социаль яклау органнарының, Күрсәтмәнең 2 пунктына һәм аңа кушымта итеп бирелүче бүләкләр исемлегенә таянып,

аңа кертелмәгән бүләкләре һәм мактаулы исемнәре булган гражданнардан “Хезмәт ветераны” исемен сорап язган гаризаларын кабул итүдән, караудан һәм аларны канәгатьләндерүдән законсыз баш тартуларын таныклый.

Күрсәтмәнең һәм Бүләкләр исемлегенең 2 пунктында исәпкә алынмаган кимчелекләр Татарстан Республикасының кайбер урындагы затларының аерым категория гражданнар алдында үз вазыйфаларын үтәмәүгә, “Ветераннар турында” Федераль закон белән бирелгән хокукларын бозуга китерә. Мондый очраклар гражданнарның Татарстан Республикасы Конституциясенең 19 (2 өлеше), 20 (1 һәм 4 өлеше), 21 һәм 46 статьялары белән гарантияләнгән хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерә. Алар нигезендә Татарстан Республикасы гражданнары, Россия Федерациясе гражданлыгына ия буларак, бертигез хокукларга һәм бурычларга хаклы, аларны гамәлгә ашыру тәртибе исә законнар белән билгеләнә. Гражданның хокуклары һәм ирекләре, өлкән яшькә җиткәч, матди тәэмин итүне дә кертеп, авырып киткән, тулысынча яисә өлешчә хезмәткә сәләтен югалткан очракта закон нигезендә һәм суд карары белән генә чикләнергә яисә туктатып торылырга мөмкин.

Күрсәтмәнең һәм Бүләкләр исемлегенең 2 пунктында Россия Федерациясенең кайбер дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре турында, хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгалары турындагы нигезләмәләрнең булмавы Татарстан Республикасы Конституциясенең 61 һәм 120 статьясы таләпләренә дә каршы килә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып һәм “Татарстан Республикасында Конституция күзәтчелеге турында” Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитеты түбәндәге нәтиҗәгә килде:

1. “Хезмәт ветераны” исеме бирү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турындагы күрсәтмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге карарының Татарстан Республикасы Конституциясенең 59 статьясына, 119 статьясының 2 пунктына һәм 122 статьясына туры килүен танырга.

2. “Хезмәт ветераны” исемен бирү өчен гаризаларны

һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге карары белән расланган күрсәтмәнең 2 пунктын, шулай ук Күрсәтмәгә "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен нигез булып торган Бүләкләр исемлегенең Россия Федерациясенең кайбер дәүләт бүләкләре һәм макталы исемнәре, РСФСРның дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре, хезмәттәге аерымлыкларның ведомство тамгалары турындагы нигезләмәләрнең исәпкә алынмавы өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 61 һәм 120 статьялары таләпләренә туры килми дип һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Конституциясенең 19 (2 өлеше), 20 (1 һәм 4 өлеше), 21 һәм 46 статьясы белән гарантияләнгән хокукларын һәм ирекләрен боза дип билгеләргә.

3. "Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге турында" Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен гаризаларны һәм документларны кабул итү, исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм бирү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган күрсәтмәнең 2 пунктының, шулай ук "Хезмәт ветераны" исемен бирү өчен нигез булып торган Бүләкләр исемлегенең Татарстан Республикасы Конституциясенең 19 (2 өлеше), 20 (1 һәм 4 өлеше), 21, 46, 61 һәм 120 статьялары, шулай ук "Ветераннар турында" Федераль законның 7, 11 һәм 22 статьялары нигезләмәләренә туры килмәүләрен бетерүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына җибәрергә, шулай ук Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитеты**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 феврале

## Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен